РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село
Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән
авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

13.03. 2020 ел №272

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2017 елның 13 декабрендәге 130 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлеген раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезендә һәм Чирмешән муниципаль районы территориясендәге кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендә булган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2017 елның 13 декабрендәге 130 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендә булган, өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлеген раслау турында» карары белән (Чирмешән муниципаль районы Советының 2018 елның 13 декабрендәге 199 номерлы, 2019 елның 14 ноябрендәге 252 номерлы, 2019 елның 13 декабрендәге 260 номерлы карарлары белән кабул

ителгән үзгәрешләр белән) расланган муниципаль милек исемлеген түбәндәге объектлар белән тулыландырырга:

| № п/п | Мөлкәт исеме | Милекнең урнашу урыны | Мәйдан (кв.м.) |
|---|---|---|---|
| 1 | Бина | ТР, Чирмешән районы, Чирмешән авылы, Беренче май урамы, 27 йорт | 42,6 |
| 2 | Котельный бинасы | ТР, Чирмешән районы, Урманасты Үтәмеш авылы, Совет урамы, 34а йорты. Кадастр номеры: 16:41:070202:160 | 133,7 |

2. «Безнең Чирмешән» («Наш Черемшан») район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасарына һәм район Советының икътисади сәясәт һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район
Башлыгы урынбасары,
Советы рәисе урынбасары Г.М. Замалтдинов